КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 20 март г.Казань № 291

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнарының гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 2022 ел, 20 октябрь, 1122 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнарының гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 2022 ел, 20 октябрь, 1122 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 14 ноябрь, 1213 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«18 яшькә кадәрге балалар арасыннан гаилә әгъзаларына һәм бер ата-анага (законлы вәкилгә) Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләре уздыра торган чараларга түләүсез йөрү хокукы бирелә.»;

3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«18 яшькә кадәрге балалар арасыннан гаилә әгъзаларына һәм бер ата-анага (законлы вәкилгә) Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан муниципаль мәдәният учреждениеләре уздыра торган чараларга түләүсез йөрү хокукы бирү.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин